КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 декабрь г.Казань № 1185

«Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасының ликвидация комиссиясе турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм фонды» коммерциячел булмаган оешмасын (алга таба - Фонд) бетерү турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Фондның ликвидация комиссиясен төзергә һәм аңа кушымта итеп бирелә торган составны расларга.

2. Фондның Ликвидация комиссиясе:

Фондны бетерү турында карар законлы көченә кергән көннән алып алты ай эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә ликвидация чараларын гамәлгә ашырырга;

Фондның мөлкәтен һәм йөкләмәләрен инвентарьлаштыруны башкарырга;

Фондның арадаш һәм ахыргы ликвидация балансларын төзергә;

Фонд хезмәткәрләрен билгеләнгән тәртиптә азат итү турында кисәтергә;

Фондның азат ителә торган хезмәткәрләренә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә.

3. Барлык ликвидация чаралары тәмамланганчы, бетерелә торган Фонд хезмәткәрләре элек үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны башкаруын дәвам итәләр һәм «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасы турында Уставта һәм тиешле вазыйфаи регламентларда билгеләнгән тиешле

юнәлешләрдәге эшләрнең торышы өчен җаваплы булалар дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2005 ел, 29 сентябрь, 473 нче;

«Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешманың башкарма директорын билгеләү турында» 2007 ел, 13 июль, 286 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2005 ел, 29 сентябрь, 473 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Уставына үзгәрешләр кертү турында» 2008 ел, 27 март, 191 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзү турында» 2005 ел, 29 сентябрь, 473 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Уставына үзгәрешләр кертү турында» 2011ел, 4 ноябрь, 916 нчы;

«Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булаган оешмасы уставын раслау турында» 2013 ел, 13 апрель, 250 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 апрель, 250 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы фәнни-техник өлкәсендә кече предприятиеләргә венчур инвестицияләрен үстерүгә ярдәм итү фонды» коммерциячел булаган оешмасы уставына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 21 апрель, 270 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин